# КАРАР

2019 елның 29 ноябре № 1

Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Иске Оча авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 28 ноябрендә һәм 2019 елның 29 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

1. «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, I төркем инвалидлары, 70 яшьтәге һәм өлкәнрәк ялгыз гражданнар, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Иске Уча авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2020 елда үзара салымны 600 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Иске Оча авылының Яр буе, Беренче Май урамы юлларына вак таш җәю; проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Иске Уча авылында җәяүлеләр күперен ремонтлау өчен пиломатериаллар сатып алу;
- урамнарны яктырту өчен энергия саклый торган лампалар сатып алу;
- Иске Уча авылында юлларны кардан чистарту;
- авыл клубы өчен музыка аппаратурасы сатып алу;
- янгын сүндерү машинасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу)?

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 180 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 108.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 106 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 2 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирде:

2. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлеге Иске Уча авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

3. Түбәндәге мәсьәләне: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, I төркем инвалидлары, 70 яшьтәге һәм өлкәнрәк ялгыз гражданнар, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Иске Уча авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2020 елда үзара салымны 600 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы

- Иске Оча авылының Яр буе, Беренче Май урамы юлларына вак таш җәю; проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Иске Уча авылында җәяүлеләр күперен ремонтлау өчен пиломатериаллар сатып алу;

- урамнарны яктырту өчен энергия саклый торган лампалар сатып алу;

- Иске Уча авылында юлларны кардан чистарту;

- авыл клубы өчен музыка аппаратурасы сатып алу;

- янгын сүндерү машинасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу)?

«РИЗА» «КАРШЫ»

- кабул ителгән дип танырга.

4. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълуматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Түбән Үрәс авыл җирлеге башлыгы Р.Х. Шамеев